# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**2023 елның 28 октябре** **№6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 28 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде, «2024 елда Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I, II төркем инвалидлардан (ялгыз яшәүчеләрдән), көндезге бүлектә укучы студентлардан, җирлек территориясендә 3 елдан артык яшәмәгән затлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?»:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту. (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Аръяк урамындагы суүткәргечне алыштыру (сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

“ РИЗА” “КАРШЫ”

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 297 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 156 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 156 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде (тыелучылар – юк).

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге составына керүче Күгәй авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.
2. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.
3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту. (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Аръяк урамындагы суүткәргечне алыштыру (сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга ( http://pravo.tatarstan.ru ) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында ( http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) шулай ук Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (администрация бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (мәдәният йорты бинасы).
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Күгәй авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Хисаметдинова